**Класс: 7 (урок 6)**

**Укытучы: Исмагилова ГүзәлДамировна**

**Программа: Ю.Н. Макарычев, Н.Г. Миндюк**

**Тема: Дәрәҗә һәм аның үзлекләре.**

**Максаты:**

**– натураль күрсәткечле дәрәҗә төшенчәсен кертү; укучыларда дәрәҗә кергән аңлатмаларны исәпләү күнекмәләрен формалаштыру.**

**(слайд 1)** Исәнмесез, укучылар! Бүгенге онлайн дәресебездә без дәрәҗә һәм аның үзлекләре белән танышырбыз.

Бертөрле берничә тапкырлаучының тапкырчыгышын дәрәҗә дип аталган аңлатма рәвешендә язарга мөмкин.

**(слайд 2)** Мәсәлән,

$4\cdot4\cdot4\cdot4\cdot4\cdot4 = 4^6$.

Тапкырлаучы – 4, тапкырлаучыларның саны – 6. 4 нең алтынчы дәрәҗәсе. Ягъни 4 не уз узенә 6 тапкыр тапкырлау дигән суз

**(слайд 3)**

$4^6$ аңлатмасында 4 саны (стрелкой указать / выделить) – дәрәҗәнең нигезе, ә 6 саны (стрелкой указать / выделить) – дәрәҗә күрсәткече.

**(слайд 4) Билгеләмә.** $a$ санының 1 дән зуррак натураль күрсәткечле дәрәҗәсе дип һәркайсы $a$ га тигез булган $n$ тапкырлаучы тапкырчыгышы $a^n$ атала. $a$ санының 1 гә тигез күрсәткечле дәрәҗәсе $a$ саны үзе була.

**(слайд 5)** $a^n = \underbrace{aaa...a}_{n\ \text{тапкыр}}$. $a$ – дәрәҗәнең нигезе, $n$ – дәрәҗәнең күрсәткече, $a^n$ - дәрәҗә.

**(слайд 6)** Санның икенче дәрәҗәсен икенче торле бу санның квадраты дип, ($a^2 = aa$), ә санның өченче дәрәҗәсен бу санның кубы дип ($a^3 = aaa$) атарбыз.

**(слайд 7)** Дәрәҗәнең кыйммәтен табуны *дәрәҗәгә күтәрү* дип атыйлар.

Дәрәҗәгә күтәрүгә мисаллар китерик:

$$3^4 = 3\cdot3\cdot3\cdot3 = 81;$$

$$0^2 = 0\cdot0 = 0;$$

$$(-6)^3 = (-6)\bullet(-6)\bullet(-6) = -216;$$

$$9^1 = 9.$$

**(слайд 8)**

Уңай санны дәрәҗәгә күтәргәндә, уңай сан килеп чыга; нульне дәрәҗәгә күтәргәндә, нуль килеп чыга.

Тискәре санны дәрәҗәгә күтәргәндә, уңай сан да, шулай ук тискәре сан да килеп чыгуы мөмкин.

**(слайд 9)** Мәсәлән,

$$(-2)^1 = -2;$$

$$(-2)^2 = (-2) \bullet (-2) = 4;$$

$$(-2)^3 = (-2) \bullet (-2) \bullet (-2) = -8;$$

$$(-2)^4 = (-2) \bullet (-2) \bullet (-2) \bullet (-2) = 16.$$

**(слайд 10)** Игътибар иткәнсездер,

Тискәре санның җөп дәрәҗәсе – уңай сан.

Тискәре санның так дәрәҗәсе – тискәре сан.

**(слайд 11)** Теләсә нинди санның квадраты уңай сан яки нульгә тигез, ягъни теләсә нинди $a$ өчен $a^2 \geq 0$ .

**(слайд 12)** Җәяләре булмаган санлы аңлатмаларның кыйммәтләрен исәпләгәндә, гамәлләрнең түбәндәге тәртибе кабул ителгән: башта дәрәҗәгә күтәрү, аннары тапкырлау һәм бүлү, ә шуннан соң гына кушу һәм алу гамәле эшләнә.

**(слайд 13)** Мәсәлән, $-2^4 + (-3)^2 \cdot 10$ аңлатмасын исәплик.

$$1)\ 2^4 = 16;$$

$$2)\ -2^4 = -16;$$

$$3)\ (-3)^2 = 9;$$

$$4) 9 \cdot 10 = 90;$$

$$5)\ -16 + 90 = 74.$$

$$-2^4 + (-3)^2 \cdot 10 = 74$$

**(слайд 14)** $a^2 a^3$ аңлатмасы нигезләре бертөрле булган ике дәрәҗәнең тапкырчыгышыннан гыйбарәт.

**(слайд 15)** Бу тапкырчыгышны нигезе шул ук булган дәрәҗә рәвешендә язарга мөмкин:

$$a^2 a^3 = (aa) \bullet (aaa) = aaaaa = a^5.$$

Димәк,

$$a^2 a^3 = a^{2+3}.$$

**(слайд 16)** Теләсә нинди $a$ саны һәм натураль $m$, $n$ саннары өчен

$$a^m a^n = a^{m+n}.$$

Бу тигезлек *дәрәҗәнең төп үзлеген* белдерә.

Дәрәҗәнең төп үзлегеннән дәрәҗәләрне тапкырлау кагыйдәсе килеп чыга:

нигезе бертөрле булган дәрәҗәләрне тапкырлаганда, нигезен элеккечә калдыралар, ә дәрәҗә күрсәткечләрен кушалар.

**(слайд 17)** $a^7 : a^3$ аңлатмасы нигезләре бертөрле булган ике дәрәҗәнең өлеше булып тора. Аның, $a \neq 0$ булганда, мәгънәсе бар.

$a^3 \bullet a^4 = a^7$ Булганлыктан, өлешнең билгеләмәсе буенча,

$a^7 : a^3 = a^4$, ягъни $a^7 : a^3 = a^{7-3}$.

**(слайд 18)** Теләсә нинди $a \neq 0$ һәм ирекле рәвештә $m > n$ булган натураль $m$ һәм $n$ саннары өчен:

$$a^m : a^n = a^{m-n}.$$

Моннан бүлү кагыйдәсе килеп чыга:

нигезләре бертөрле булган дәрәҗәләрне бүлгәндә, нигезне элеккечә калдыралар, ә бүленүченең дәрәҗә күрсәткеченнән бүлүченең дәрәҗә күрсәткечен алалар.

**(слайд 19)** Әгәр бу кагыйдәне $a^n : a^n$ өлешенә карат куллансак,

$$a^n : a^n = a^{n-n} = a^0$$

килеп чыгар.

Теләсә нинди $a \neq 0$ һәм натураль $n$ өчен

$$a^n : a^n = 1$$

булганга , $a \neq 0$ өчен

$$a^0 = 1$$

дип саныйлар.

Билгеләмә. Нульгә тигез булмаган санның нуленче дәрәҗәсе бергә тигез.

**(слайд 20)** $(ab)^4$ аңлатмасы $a$ һәм $b$ тапкырлаучылары тапкырчыгышының дәрәҗәсе була. Бу аңлатманы $a$ һәм $b$ дәрәҗәләренең тапкырчыгышы рәвешендә күрсәтергә мөмкин:

$$(ab)^4 = ab \cdot ab \cdot ab \cdot ab = (aaaa) \bullet (bbbb) = a^4 b^4.$$

Димәк,

$$(ab)^4 = a^4 b^4.$$

Теләсә нинди $a$, $b$ һәм ирекле рәвештә алынган натураль $n$ саны өчен

$$(ab)^n = a^n b^n.$$

Моннан шундый кагыйдә чыга:

Тапкырчыгышны дәрәҗәгә күтәргәндә, һәр тапкырлаучыны шул дәрәҗәгә күтәреп, нәтиҗәне тапкырлыйлар.

**(слайд 21)** $\left(a^5\right)^3$ аңлатмасы – нигезе үзе дәрәҗә булган дәрәҗә ул. Бу аңлатманы нигезе $a$ булган дәрәҗә рәвешендә күрсәтергә мөмкин:

$$\left(a^5\right)^3 = a^5 \bullet a^5 \bullet a^5 = a^{5+5+5} = a^{5\cdot3}.$$

Теләсә нинди $a$ саны һәм ирекле натураль $m$ һәм $n$ саннары өчен түбәндәге тигезлек дөрес:

$$\left(a^m\right)^n = a^{mn}.$$

Әлеге үзлектән алдагы кагыйдә чыга:

дәрәҗәне дәрәҗәгә күтәргәндә, нигезен үзгәрешсез калдырып, дәрәҗә күрсәткечләрен тапкырлыйлар.

**(слайд 22)** Шулай итеп, дәрәҗәнең барлык үзлекләрен карап чыктык:

1) $a^m a^n = a^{m+n}$ яки $a^{m+n} = a^m a^n$;
2) $a^m : a^n = a^{m-n}$ яки $a^{m-n} = a^m : a^n$;
3) $(ab)^n = a^n b^n$ яки $a^n b^n = (ab)^n$;
4) $\left(a^m\right)^n = a^{mn}$ яки $a^{mn} = \left(a^m\right)^n$;
5) $a^0 = 1$.

Дәрәҗәнең үзлекләре белән таныштык, ә хәзер практик биремнәргә күчик.

**(слайд 23)** 1. Тапкырчыгышны дәрәҗә рәвешендә языгыз:

а) $5\cdot5\cdot5\cdot5\cdot5\cdot5 = 5^6$;

б) $25\cdot25\cdot25 = 25^3$;

в) $\underbrace{aaa...a}_{12\ \text{тапкыр}} = a^{12}$.

**(слайд 24)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 25)** 2. Дәрәҗә төшенчәсен кулланып, хәрефле аңлатманы кыскарак языгыз:

а) $(-y) \bullet (-y) \bullet (-y) \bullet (-y) = (-y)^4$;

б) $-y\cdot y\cdot y\cdot y = -y^4$;

в) $(ab) \bullet (ab) \bullet (ab) \bullet (ab) \bullet (ab) = (ab)^5$;

г) $-5m\cdot m\cdot 2\cdot n\cdot n\cdot n = -10m^2n^3$;

д) $(p - q) \bullet (p - q) \bullet (p - q) \bullet (p - q) = (p - q)^{4}$;

е) $p - q \cdot q \cdot q \cdot q \cdot q \cdot q = p - q^{6}$.

**(слайд 26)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 27)** 3. Дәрәҗәнең нигезен һәм күрсәткечен әйтегез, анлатманың кыйммәтен исәпләгез:

а) $5^{3} = 5\cdot5\cdot5 = 125$; нигезе – 5 , күрсәткече – 3.

б) $(-4)^{2} = (-4) \bullet (-4) = 16$; нигезе – $(-4)$ , күрсәткече – 2.

в) $\left(-\frac{2}{3}\right)^{3} = \left(-\frac{2}{3}\right) \bullet \left(-\frac{2}{3}\right) \bullet \left(-\frac{2}{3}\right) = -\frac{8}{27}$; нигезе – $(-\frac{2}{3})$ , күрсәткече – 3.

г) $\left(2\frac{1}{2}\right)^{2} = \left(\frac{5}{2}\right)^{2} = \left(\frac{5}{2}\right) \bullet \left(\frac{5}{2}\right) = \frac{25}{4} = 6\frac{1}{4}$; нигезе – $(2\frac{1}{2})$ , күрсәткече – 2.

д) $(-3,6)^{1} = -3,6$. нигезе – $(-3,6)$ , күрсәткече – 1.

**(слайд 28)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 29)** 4. Тапкырчыгышны дәрәҗә рәвешендә языгыз:

а) $2^{7} \bullet 2^{8} = 2^{7+8} = 2^{15}$;

б) $(-5)^{98} \bullet (-5) = (-5)^{98+1} = (-5)^{99}$;

в) $0,4^{5} \bullet 0,4^{25} = 0,4^{5+25} = 0,4^{30}$;

г) $c\cdot c^{457} = c^{1+457} = c^{458}$;

д) $y^{120} \bullet y^{80} = y^{120+80} = y^{200}$;

е) $n^{14}\cdot n\cdot n^{20} = n^{14+1+20} = n^{35}$;

**(слайд 30)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 31)** 5. Бүлегез:

а) $3^{9} : 3^{7} = 3^{9-7} = 3^{2} = 9$;

б) $(-2)^{100} : (-2)^{99} = (-2)^{100-99} = (-2)^{1} = -2$;

в) $0,8^{14} : 0,8^{12} = 0,8^{14-12} = 0,8^{2} = 0,64$;

г) $x^{8} : x^{3} = x^{8-3} = x^{5}$;

д) $y^{15} : y^{15} = y^{15-15} = y^{0} = 1$;

е) $a^{103} : a^{79} = a^{103-79} = a^{24}$;

**(слайд 32)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 33)** 6. Дәрәҗә рәвешендә күрсәтегез:

а) $5^{8}\cdot25 = 5^{8} \bullet 5^{2} = 5^{10}$;

б) $3^{12}\cdot27 = 3^{12} \bullet 3^{3} = 3^{15}$;

в) $6^{15}\cdot36 = 6^{15} \bullet 6^{2} = 6^{17}$;

г) $2^{9}\cdot32 = 2^{9} \bullet 2^{5} = 2^{14}$;

**(слайд 34)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 35)** 7. Дәрәҗәгә күтәрегез:

а) $(xy)^5 = x^5 y^5$;

б) $(-2ab)^3 = (-2)^3 a^3 b^3 = -8a^3 b^3$;

в) $(-3y)^2 = (-3)^2 y^2 = 9y^2$;

г) $(-am)^3 = (-1)^3 a^3 m^3 = -a^3 m^3$.

**(слайд 36)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 37)** 8. Тапкырчыгышны дәрәҗә рәвешендә күрсәтегез:

а) $a^2 b^2 = (ab)^2$;

б) $x^5 y^5 z^5 = (xyz)^5$;

в) $16y^4 = 2^4 y^4 = (2y)^4$;

г) $9a^2 = 3^2 a^2 = (3a)^2$.

**(слайд 38)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 39)** 9. Аңлатманы нигезе $a$ булган дәрәҗә рәвешендә күрсәтегез:

а) $\left(a^2\right)^5 = a^{2\cdot5} = a^{10}$;

б) $a^2 \bullet a^5 = a^{2+5} = a^7$;

в) $\left(a^4\right)^3 \bullet a^5 = a^{12} \bullet a^5 = a^{17}$;

г) $\left(a^k\right)^n = a^{kn}$.

**(слайд 40)** Җавапларыгызны тикшерегез.

**(слайд 41)** 10.Исәпләгез:

а) $(-3)^4 = (-3) \bullet (-3) \bullet (-3) \bullet (-3) = 81$;

б) $-3^4 = -3\cdot3\cdot3\cdot3 = -81$;

в) $2^4 \bullet 5^4 = (2\cdot5)^4 = 10^4 = 10000$;

г) $5^1 = 5$;

д) $6^0 = 1$.

**(слайд 42)** Җавапларыгызны тикшерегез.